**СОВЕТ**
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
**АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Кооперативная, д. 22, с.Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

Утар-Аты авыл җирлеге Советы карары

«10» сентябрь 2024 ел. №125

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 104 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибенең бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, Утар-Аты авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының 29.11.2023, № 104 номерлы Утар-Аты авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: 2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« 4) 2025-2027 еллар чорына карата 1,2 процент: гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артык булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслар), исемлеккә кертелгән биналар Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә;».
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карар Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта һәм Арча муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева